**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

07 08 2026 ел Яр Чаллы ш. №2704

«Эксперт комиссиясен төзү турында» Башкарма комитетының 2016 елның 24 августындагы 3438 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 10 февралендәге 120 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «Эксперт комиссиясен төзү турында» Башкарма комитетының 2016 елның 24 августындагы 3438 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары (урынбасарлары), комиссиянең җаваплы секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

Комиссия әгъзалары булып профилактика системасы органнары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) тора, шулай ук башка дәүләт (муниципаль) органнары һәм учреждениеләре вәкилләре, иҗтимагый берләшмәләр, дини конфессияләр вәкилләре, балигъ булмаганнар белән эшләү тәҗрибәсе булган гражданнар, тиешле вәкиллекле органнар депутатлары, башка кызыксынган затлар булырга мөмкин.

Комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, җаваплы секретаре һәм әгъзасы булып 21 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы була ала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов